The lyrical hero is delusioned and embittered, exhausted by his inability to change the state of things. The emotions, experienced by the lyrical hero, are revealed with the help of images of the constantly moving Earth and the old plate, the old plate symbolizes the difference between the psychological and biological age of the lyrical hero. The poem ends with the apology of the lyrical hero, who realizes his helplessness with respect to the state of affairs around him.

This type of a lyrical hero continues to appear in the works of Suleiman, R. Aimet, and L. Gibadullina. Suleiman's lyrical hero experiences the chaos of emotions, which are generally strong, their sequence and transition from one to another are extreme:

*Ap-achyk,*
*Ap-ak,*
*Yap-yakty -*
*Әҗәl.*
*Butalchyk,*
*Cap-car,*
*Karaңgy -*
*Yashәү.*
*Homer bue tartylabyz*
*Achyklykka,*
*Aklykka,*
*Yaktylykka.*
Obvious,
White,
Bright –
Death.
Confused,
Black,
Dark –
Life .
We strive all our life
Towards clarity,
Purity,
Light [Sөlәiman, p. 109].

In R. Aimet's poems, the emotions, experienced by the lyrical hero in this chaotic life, are depicted using the stream of consciousness method. The lyrical hero, who cannot find happiness in life, distances himself from people ("Min zhirlarga tushtem" ("I Fell to the Ground"), (2001), realizing that he cannnot change this state of things and plunging into the world of dreams ("Ezlamagez mine" ("Don't Look for Me"), (2000).

Postmodern studies are gradually moving from the concept of identity to poetic aspects. D. Zagidullina notes that such works tend to depict the world, the life around as a complex theatrical show, as the aesthetics of flickering (flickering of motifs), versatility, and fragmentation of scenes [Zagidullina, Tatarskaia poezia…., p. 190].

We find these methods in L. Gibadullina's poems. Her poems, united by the opening lines "Ber karyshka – ber zhan, ber karyshka – molderama tuly mizgel bary" ("One glance – one soul, one glance –a single moment") are characterized by the aesthetics of repetition, the repetition of the same elements and images leads to new semantic associations, there is a departure from illusory images

and coherent compositions. The poetess resorts to figurative language, she enriches widely used images with new meanings, expanding their semantic boundaries, placing incompatible images next to each other. It is these qualities that make it possible to describe different feelings of love– divine love, love for one's beloved, love for one's nation, elevating the soul of a person who knows how to combine these moments. The same feature is observed in the poem "Bu gavam sagyshtan yaralgan" ("These People Are Born of Sorrow"), the repetition of white and black images leads to different meanings, proving that every value in life is an illusion.

The striving for lyrical and symbolic images, details and intertextual connections is at the center of Yu. Minnullina's work. Even the titles of the poems complement the meaning collected from separate fragments. At the same time, the titles of her poems emphasize the main idea, and often this title complements the dominant meaning, hidden in the structure of the work. The poem "Bozly tarazada barmak eze" ("A Fingerprint on an Icy Window Pane") describes a picture of everyday life: the lyrical hero is gazing at the city. A typical mosaic image is observed: it is winter, a grandmother is knitting socks for her grandson, a man is leaving his house in front of the mosque to go to town at night. These fragments, these details, lined up individually, summarize the author's opinion in the last two lines:

*Tonyklana bar shəhər ...*
*tynyӊ belən kylytmasaӊ əgər.*
The city darkens ...
if you don't warm it with your breath [Miӊnullina,p. 13].

According to the author, everyone creates their own environment, determines the meaning of life in this environment and their place in life, which should flash like lightning, all these things are written by fingerprints on the window pane.

A similar image and motif are in E. Bainazarov's poem "Bez" ("We") (2014). In general, this work of the young poet possesses the striking power of figurative description, he loves complex, unexpected environments (for example, "Kechkena magynasezlek" ("Small Nonsense")), uses editing strategies, which are rarely used in compositional techniques. In his poem "Muklangan divarlar zhylysyn kyzgandy" ("The Walls Overgrown with Moss Didn't Want to Give Warmth") (2014), the reader is confronted with the images and epithets-metaphors such as a wall covered with moss, or chilly lips that convey the coolness of love.

Associative imagery is a characteristic feature of the works by R. Harris. If we analyze his poem "Kara tugarak" ("A Black Circle"), built on multilayered, multi-valued metaphorical, and symbolic images, reminiscent of poetic riddles that readers are supposed to solve by themselves, we will note that this poem contains relevant unexpected twists and complex comparisons, that the poet seek for the meaning of one phenomenon in another, that the discovery of the meaning of the first phenomenon occurs with the help of the third phenomenon – these are the features of R. Haris's lyrical reasoning. In his poem, the image of Malevich's "Black Square" plays the role of a poetic metaphor, and black, green, yellow, and red lines are used to evaluate certain moments of human life. Through the proximity of the black side / infinity, the author expresses eternity, noting that the human mind sets the limit of the eternal / the perishable. According to the poet, during his lifetime man comes from eternity, constantly striving for eternity, inaccessible to his mind, and this striving forms a circle of human life. These attempts to evaluate life (the world) and man through associative images are found in Suleiman's poems "Tatar bishegenda Tatar balasy" ("A Tatar Child in a Tatar Cradle"), "Kanatlarny – kauryi kalam ittem" ("I Made Wings with a Pen"), and in the collection of his poems "Yugalyr kuk bu mizgel" ("It Seems This Moment Will Be Missed").

Contemporary Tatar poetry is conducting large-scale searches for genre transformations and its revival. The genre of the poem is especially unique in this respect. In Tatar poetry, a number of poems date back to the early 20$^{th}$ century, continuing the traditional style developed by R. Karim, S. Hakim and others: the poems of R. Minnullin "Suyu" ("Love"), F. Gilyazov "Iske Kazan – Kirman nigeze" ("Old Kazan is the Basis of the Fortress"), R. Valieva "Yaraly Yazmysh" ("Wounded Destiny"), etc., in which the lyrical hero takes on the function of a storyteller, convey his emotions and experiences related to this or that life event, his feeling of love. R. Valieva's poem tells the love story of Mirkhaidar and Gulnisa and the tragedy of the war that make the lyrical hero suffer; R. Minnullin's work tells about a person's life and is focused on the appreciation of love. It is noteworthy that M. Mirza's poem "Kysir Garif" ("Cruel Garif"), devoted to the theme of war and a century-old story, supplements the list of poems written on

the theme of war, which has lost its relevance in recent years.

The second group of Tatar poems, which have appeared in recent years, attempts to synthesize different trends. This cohesion is achieved by combining the artistic text with other texts within – through intertextuality. Y. Minnullina's poem "Otukan zhirenda ut yana" ("Fire Is Burning on the Land of Otuken") (2014) was created as the synthesis of literary layers. The people's tragedy, caused by the loss of statehood, is described through the synthesis of various layers, intertext techniques. Here, R. Harris's poems come to the fore, enriched with intellectual techniques. His poem-treatise "Yaza bashla!" ("Start Writing!") (2017) possesses philosophical content; the concepts of poet, poem, and writing are discussed throughout the entire work, conveying the poet's main philosophical ideas: the poem should be about honesty, morality, faith, spirituality, perseverance, and love for the people. R. Harris's poem "Uba" ("The Old Woman") (2017) is structurally a synthesis of different literary layers. This synthesis helps to unite within the framework of one poem different problems, political and mythological details, political and social ideas, ideology and human fate, a tragedy caused by the system, a tragedy experienced by people and related to philosophical issues – the meaning of life and the example of humanity. The poet introduces the lyrics of songs about Stalin, the phrases, used as political slogans, and shows the inner resistance of the lyrical hero by destroying the myth. The plot about a tractor driver and his rival villager, who was forced to suffer in the gulag prisons, is only the first layer of events. In the secondary associative layer, the poet talks about the impact of the tragedy of that period on the fate of people, he thinks that those bloody years will be preserved in the memory of generations. In this regard, the image of an old woman acquires the status of a complex symbolic integrity: it is perceived as the depth of the country, the depth of history, people's memory, and tragic events in life. The triptych of F. Tarkhanova "Halkym Minem" ("My People") (2017) expands the genre boundaries of Tatar poetry. The genre form of a triptych usually combines three verses around a common idea. F. Tarkhanova's work can be divided into three chapters: "Spirit and Faith", "Sadness", and "Language". However, the internal logic of this division is revealed in the subjective layer, and these three concepts are defined as the most basic qualities that concern the nation and make Tatars be Tatars.

In Tatar poetry after the 1990s, the traditions, developed by R. Gatash, continue - stylization, transformation and revival of oriental genres, similar to oriental poetic texts. A. Sattar's rubais are structurally built in accordance with oriental literary traditions. In every rubai of the author, as in the case of oriental traditions, moral issues are at the forefront; social laws are approved or rejected in the philosophical and ethical terms, and the motives for spiritual and moral renewal find a great response. Both F. Davletbaev's quatrains, R. Idiyatullin's poem "Tormysh" ("Life"), and D. Garifullin's quatrains are perceived as stylization of the tale and rubai genres.

The five-verse genre form reappears in the works of M. Mirza, in the continuation of his poetic cycle "Adam balasy" ("Human"). Widely used in oriental poetry, known as "Tufan strophas" ("Tufan strophe") in national poetry, the five-verse is used by M. Mirza in a completely different way to express the feelings of the lyrical hero, the author's opinion, the sound of the text, its melody, and the emotional impact. The use of proverbs and sayings, an attempt to line up the lines of a poem in the tradition of wise sayings, his very subtle irony – all these features of his work ensure its uniqueness and originality:

*Tyelgannan tyela beləbez,*
*Ana səte belən kyngənbez.*
*Urtak vatan əchen, kirək ikən,*
*Oҗçmakhtan təmugka kerəbez, -*
*Shundy batyr, shundy kundym bez?!*

We know what is forbidden,
We took it in with our mother's milk.
For our own homeland, if necessary
From heaven to hell we'll go, –
Are we really so brave and so obedient?! [Mirza, p. 20]

Therefore, these works are not considered to be a stylization of the Eastern five-verses, but a kind of the genre of Tatar poetry.

## Results

1. Poetry studies at the beginning of the 21$^{st}$ century mainly focused not on content but on the concept of form and identity, and led poetry to the new paths of development, while following the mainstream.

2. Realistic works are characterized by the strengthened critical element and the recurrent national theme, the civic position is enriched by social philosophy. On the one hand, these ideas and motifs are expressed through the lyrical rebellious hero, who, seeing injustice in life and not being

able to directly oppose it, lives in contradiction with himself, in a state of inner anxiety; on the other hand, he desires to change the world, he demonstrates an active life position. Three literary approaches to the transmission of critical values are activated: hidden content, demythologization, and intertextuality.

3. Philosophical generalizations, reflections on the meaning of life, the value of life, religious motifs remain strong in romantic works due to their active philosophical lyricism and the major aesthetic function. In such works, the lyrical hero, with his rich inner world, is a philosopher searching for life values. These samples of romantic creativity are characterized by the poetic activity of oriental symbolic details-images, the renewal of folklore images, the use of folk modes, and stylization based on folk songs.

4. The works, written on the wave of post-realism, have caused changes in civic lyricism; in such poetry, the combination of civic and philosophical positions deepens the content. The deeper is the penetration of postmodern techniques into national literature, the more intensive is the search for new forms, the new lyrical hero – the chain of the nation: to change the idea of the lyrical hero using civic lyrical trends. Although the poetry of the 1990s continued to use the lyrical hero who rose up to fight for the happiness of the nation, the poetry of that period took on a new modification. This lyrical hero, on the one hand, acted like the son of his people, and on the other, he “stood out” and embarked on the path of “externalizing” the situation.

5. Postmodern studies begin with a lyrical hero who cannot find his path in this chaotic life, the poets strive to portray the world and life as a complex theatrical performance, using the aesthetics of flickering (flickering of motifs), versatility, and fragmentation.

## Conclusions

Thus, the poetry of the early 21st century can be defined as a poetic period of serious research into the field of form. This quest begins with a lyrical hero, who cannot find his path in a chaotic life, striving to portray the world and life as a complex, theatrical performance, using the aesthetics of flickering (flickering of motifs), plurality and fragmentation, and unification. Thus, the ongoing research into the poetry of the early 21st century, especially in terms of content, is strong in conveying the concept of form and identity, it has contributed to the mainstream in poetry leading it along the new paths of development.

**References**

Aimet, A. (2017). *Harber mizgele izge* [Each Moment Is Holy]. Kazan utlary. No. 12, pp. 76–79. (In Tatar)

Borukhov, B. (1992). *Vvedenie v motiviruyuschuyu poetiku* [An Introduction to Motivational Poetics]. Filologicheskaia germenevtika i obschaia stilistika. Pp. 5–28. Tver, izd-vo Tverskogo un-ta. (In Russian)

Galiev, M. (2014). *Chydam tau da, uzan da bez* [We Are Both a Strong Mountain and a Valley]. Kazan utlary. No. 4, p. 68. (In Tatar)

Galiev, M. (2018). *Su kargyshy* [The Curse of Water]. 158 p. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

Gambar, N. (2007). *Yashau tamyry* [Root of Life]. 351 p. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

Iusupova, N. M. (2018). *2017 nche elda Tatar shigriyate: stil tendenctiyalare ham zhanrlar useshe* [Tatar Poetry in 2017: Style Trends and the Development of Genres]. Fanni Tatarstan. No. 1, pp. 66–75. (In Tatar)

Iusupova, N. M., Ibragimov, M. I. (2012). *Sovremennaia Tatarskaia poeziia* [Modern Tatar Poetry]. Natsionalnie literatury respublic Povolzhia (1980–2010) [National Literatures of the Volga Region (1980–2010)]. Pp. 118–123. Barnaul. (In Russian)

Latypova, A. V., Saifulina, F. S., Sheianova, S. V. (2019). *Genre Paradigm Features in R. Idiatullin’s Poetry.* Turismo, Estudos &Práticas (UERN), Mossoró/RN, Caderno Suplementar. T. 1, pp.1– 7. (In English)

Latypova, A., Khabutdinova, M., Zakirzianov, A. (2017). *The Question about Ethnic Identity of the Modern Tatar Poets of the Republic of Bashkortostan (based on the lyrics of Maris Nazirov).* The Turkish Online Journal of Design, Art and Communica-tion. TOJDAC. April Special Edition. Pp. 917 – 921. (In English)

Minnullina, Yu. (2011). *Kuk tirmase* [Firmament]. 47 p. Kazan, Tatar publishing house. (In Tatar)

Mirza, M. (2016). *Beruzema ber dingez* [All the Sea to Me Alone]. 222 p. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

*Sovremennaia Russkaia literatura* (2005) [Modern Russian Literature (the 1990s– early 21st century)]. S. I. Timina, V. E. Vasilyev, O. Yu. Voronina, etc. 352 p. Saint-Petersburg, “Academiia”. (In Russian)

*Suleiman Sutela yomgak…(*2011) [The Ball Is Unwound...]. 209 p. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

Tarkhanova, F. (2017). *Kapka* [Gates]. Kazan utlary. No. 5, p. 99. (In Tatar)

*Terminologiia sovremennogo zarubezhnogo literaturovedeniia (Strany Zapadnoi Evropy i SSHA)* (1992) [Terminology of Modern Foreign Literary Criticism. (Countries of Western Europe and the USA)]. Ilin I. P., Tsurganova E. A. 218 p. INION. (In Russian)

Zagidullina, D. F. (2017). *Tatarskaia poeziia rubezha 20–21 vekov(1986–2015): esteticheskie orientiry I khudozhestvennye poiski* [Tatar Poetry at the Turn of the 20th–21st Centuries (1986–2015): Aesthetic

Guidelines and Artistic Searches]. 268 p. Kazan, Fan. (In Russian)

Zagidullina, D. F. (2020). *Tatarskaia literatura 20-nach.21 v.: "myagkost" modernizma-avangarda-postmodernizma (k postanovke problemy)* [Tatar Literature in the 20th–early 21st Centuries: "Softness" of Modernism-Avantgarde-Postmodernism (on the problem)]. 256 p. Kazan, ILLA. (In Russian)

Zeidulla, R. (2017). *Avaz* [Sound]. Kazan utlary. No. 5, p. 10. (In Tatar)

Zeidulla, R. (2017). *Yul* [A Road]. Kazan utlary. No. 5, p. 6. (In Tatar)

Zulkarnai, L. (2013). *Mangelektan isa zhil...* [The Wind Blows from Eternity]. 290 p. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

---

# XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЯҢАРЫШ ЮЛЛАРЫ

**Нурфия Марс кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
faikovich@mail.ru.

Мәкалә, соңгы елларда иҗат ителгән шигъри әсәрләр мисалында, хәзерге татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләрен ачыклауга, традицияләр һәм яңарыш юлларын билгеләүгә йөз тотып язылган. Герменевтик якын килеп, күп әсәрләр беренче тапкыр фәнни нигездә анализлана, аерым әдипләрнең, әсәрләрнең әдәби барыштагы урыны, алып килгән яңалыгы төгәлләштерелә, поэзиядә барган үзгәрешләрнең нигезләре, яңалыкларның формалашу үзенчәлеге билгеләнә. Бу мәкаләнең яңалыгын һәм актуальлеген билгели. Тикшеренүнең төп максаты – хәзерге татар шигъриятендәге төп тенденцияләрне аерып кую, иҗат юнәлеше, жанр парадигмасы, тематик-проблематик, поэтик эзләнүләрдә традицияләрнең дәвам ителешен һәм яңарыш юлларын билгеләү, шәхес концепциясенең үзгәреш нигезләрен ачыклау. Эзләнүләр нәтиҗәсендә XXI гасыр башы шигъриятендә барган үзгәрешләрнең, эчтәлек ягыннан бигрәк, форма һәм шәхес концепциясе бирелешендә көчле булып, төп магистраль юлны саклаган хәлдә, шигъриятне өр-яңа үсеш сукмакларына алып чыгуы билгеләнә. Реалистик әсәрләрдә тәнкыйди башлангычның көчәюе, милли тематиканың активлыгы, гражданлык позициясенең иҗтимагый фәлсәфә белән баюы, әлеге яңарышның лирик герой концепциясе белән янәшәдә баруы ачыклана. Тәнкыйди бәяне җиткерүдә өч әдәби алым – яшерен эчтәлек, демифологизация һәм интертекстуальлек аерып чыгарыла. Постреализмның гражданлык позициясен фәлсәфилек белән тирәнәйтүе аша татар поэзиясенә жанр, форма яңалыклары алып килүе, лирик герой концепциясен үзгәртүе билгеләнә. Постмодернистик эзләнүләрнең тәртипсез тормышта яктылык тапмаган лирик геройдан башланып китеп, дөньяны, яшәешне катлаулы бербөтен, театраль тамаша итеп сурәтләргә омтылу, җемелдәү эстетикасы (мотивларның җемелдәп алуы), күпъяклылык һәм фрагментарлык, ассоциативлык күренешләре аша чагылыш табуы дәлилләнә. Романтик әсәрләрдә фәлсәфи гомумиләштерүләр, яшәү мәгънәсенә, яшәү кыйммәтенә мөнәсәбәтле уйлануларның, дини мотивларның көчле булуы, фәлсәфи лириканың активлашуы, эстетик функциянең көчәюе, шәхес концепциясенең үзгәреше ачыклана.

**Төп төшенчәләр:** хәзерге татар шигърияте, лирик герой концепциясе, образ, жанр, иҗат юнәлеше, әдәби алым.

## Кереш

XXI гасыр башы татар шигъриятендәге үсеш-үзгәреш, бер яктан, 1990 еллардагы рухи һәм милли яңарышның, икенче яктан, 1960-1980 еллардагы шигъри күтәрелешнең матур нәтиҗәсе буларак дәвам итә. Традиция һәм яңачалыкның үзара бәйләнеп баруы, керешеп китүе бу чорда да актуаль булып кала.

XXI гасыр башы татар шигъриятендә төп стиль тенденцияләре буларак түбәндәге сыйфатлар аерылып чыга: романтик поэзиядә лирик-эмоциональ, лирик-фәлсәфи башлангычның, яшәеш кыйммәтләре турында уйлануларның дәвам ителүе, шуңа бәйле күңел һәм фәлсәфи лириканың үстерелүе; романтик материалда иҗтимагый детерминация алымына мөрәҗәгать итү аша постромантизмның

активлашуы, бу юнәлештәге әсәрләрдә милли тематиканың көчле яңгыраш алуы; реалистик дулкында тәнкыйди башлангычның көчәюе, яшерен эчтәлек, демифологизация, интертекстуальлек алымнары аша ачылган субъектив катламның җәмгыятькә, милли көнитешкә хас проблемаларны калкытып куюга, иҗтимагый барышның шәхескә, кеше тормышына йогынтысын ачып бирүгә йөз тотуы, бу юлда гражданлык лирикасының активлашуы; форма, шәхес концепциясе өлкәсендә эзләнүләрнең алга чыгуы һәм постмодернистик шигъриятнең мәйдан яулавы. Бу сыйфат-хасиятләр хәзерге чор татар поэзиясендә яшәеш кануннарын барлаган, кешене олы кыйммәт итеп күтәргән яисә тормыш-яшәеш закончалыкларын тәнкыйть утына алган яңа әдәби модельнең төзелүенә китерә [Юсупова, б. 66]. Әлеге модель, үз чиратында, лирик герой концепциясенең үзгәрешенә, аның яңа үзенчәлекләр белән баюына, әдәби әсәрләрдәге дөнья сурәтенең алмашынуына йогынты ясый. Шуның белән янәшәдә шигъриятнең жанрлар төрлелеге ягыннан да бай һәм үзенчәлекле булуы, бу өлкәдә эзләнүләрнең, стильләштерү сыйфатының, сәнгати экспериментларның урын алуы күзгә ташлана. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, XX–XXI гасыр чиге татар әдәбияты ул – шәхси стильләр, язу формасы, эстетик модельләр аша мәдәни парадигмалар төрлелегенә омтылган, иҗади йөзен булдырган әдәбият [Загидуллина, 2020, с. 135].

Хәзерге татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш аспектлары Д.Ф. Заһидуллина тарафыннан өйрәнелеп, аның эзләнүләрендә татар шигъриятенең эстетик ориентирлары ачыклана һәм сәнгати эзләнүләр тикшерелә [Загидуллина, 2017], [Загидуллина, 2020]. Н.М. Юсупова [Юсупова, 2018], [Юсупова, 2012] хезмәтләрендә хәзерге татар поэзиясендә иҗат юнәлеше, агымнарының үзгәреше, эчтәлек һәм форма яңарышы, лирик герой концепциясенең үсеш үзенчәлеге тикшерү объектына әверелә. А.Латыйпова мәкаләләрендә Башкортостандагы хәзерге татар шигърияте дөнья сурәте һәм жанр яссылыгында бәяләнә [Latypova, Sayfulina..., 2019], [Latypova, Khabutdinova..., 2017].

## Хезмәтнең методологик нигезе

Хезмәтнең методологик нигезе итеп герменевтик эзләнүләр алынды [Терминология...., с. 11]. Методик яктан Б.Л. Борухов тәкъдим иткән «мотивлаштырылган поэтика» файдаланылды. Ул аңлатуны фәнни эшчәнлекнең ахыргы максаты буларак карый һәм әдәби текстны анализлау өчен төп метод итеп канун (закон) нигезендә аңлатуны аерып чыгара, аны текстны мотивацияләү дип атый [Борухов]. Б.Л. Борухов мотивацияләүнең мәдәни, конвенциаль, менталь төрләрен билгели [Борухов, с. 13]. Мәкаләне язу барышында без аның конвенциаль төре белән эш иттек. Бу төрдә әдәби күренеш булган текст һәр чорда үз закон һәм конвенцияләренә буйсынып дөньяга чыга дип карала. Конвенциаль мотивацияләү хәзерге татар поэзиясенең төп үсеш тенденцияләрен аерып чыгарырга, анда традицияләрнең дәвам ителешен һәм яңарыш юлларын, аларның нигезен, үзенчәлеген аңлатырга мөмкинлек бирә.

## Фикер алышу

Хәзерге чор шигъриятендә реализмның үз позицияләрен саклап калуы күренә: шигъри әсәрләр, традицияләрне дәвам итеп, иҗтимагый тормышка, җәмгыятьтәге вазгыятькә, милләт тормышына аерым игътибар бирә, заманга, милли сәясәткә хас проблемаларны калкытып куя; лирик геройның гражданлык позициясен ассызыклый. Традицион юнәлешне дәвам итеп язылган әсәрләрдә шәхес концепциясен иҗтимагый кануннарны аңларга-бәяләргә омтылучы гражданин лирик герой билгели, аның ике тибы урын ала. Бер яктан, ул 1960-1980 еллар татар поэзиясе традицияләрендә, тормыштагы хаксызлыкны күреп-аңлап та, турыдан-туры каршы чыгарга үзендә көч тапмаган, үз-үзе белән каршылыкта, эчке борчылу халәтендә яшәүче лирик герой калыбын үстереп алып китә. Р. Аймәт «Тормыш поезды» (2017) шигырендә бу тип лирик геройны «чылбырланган вагоннарда барган зынҗырлы җаннар» [Аймәт, б. 76] сурәте аша чагылдырып бирә. Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Р. Низами, Р. Аймәт, И. Гыйләҗев, Г. Рәхим һ.б. шигырьләрендә шушы тип лирик герой алга чыга һәм шагыйрьләр тарафыннан чор кешесенең эчке халәте сурәтендә тәкъдим ителә. Әлеге каршылык әдипләрнең җәмгыятьтәге вазгыятькә бәйле сызлануын җиткерүгә дә йөз тота.

Гражданлык лирикасына мөнәсәбәтле икенче төркем шигырьләрдә хөр фикерле, актив, вакыты белән бунтарь, гыйсъянчы лирик герой калкулана, тормыш-яшәешкә, үзе яшәгән җәмгыятькә һәм анда барган үзгәрешләргә, милли мәсьәләләргә үз бәясен, фикерен, мөнәсәбәтен ишеттерергә омтыла, бу исә тәнкыйди башлангычка юл бирә. «Сөенмәсеннәр,

таптадык, диеп, / Баш күтәрербез көлдән яралып!» [Зәйдулла, 2017, б. 10] дип аваз салган бунтарь, гыйсъянчы герой, нигездә, Р. Зәйдулла, Н. Сафина, Р. Мөхәммәтшин иҗатларында алга чыга. Ул аеруча тел мәсьәләсенә бәйле вакыйгаларга мөнәсәбәттә активлашып китә. Мисал өчен, XX гасыр ахырында символик, шартлы сурәтлелеккә борылган Р. Зәйдулланың соңгы елларда язылган шигырьләрендә кабат бунтарь, гыйсъянчы лирик герой традициясе яңартыла, экспрессионизм алымнарыннан, лирик геройның тышкы тирәлек белән каршылыкка керүе, тормышны караңгы буяуларда сурәтләү, тормышка аңлаешсыз, дошмани бәя бирү, хисләр киеренкелеге, «Тартышып яшибез һаман да, / Хак бар яшәргә безнең дә!» [Зәйдулла, 2017, б. 6] дип, күнегелгән тәртипләргә, сәясәткә, мәдәни хәл-халәткә, сәяси тәртипләргә каршы чыгу сыйфатлары күзәтелә. Охшаш мотивлар Н.Сафина иҗатында, Р. Мөхәммәтшинның «Бер генә», «Васыять», «Вакыт җәнаплары» кебек шигырьләрендә дә күзәтелә, һәр образ, деталь, өзек-өзек сурәтләр шигырь структурасында лирик геройның дөньяга ачуүпкә, ләгънәтен ачуга, тәэсирлелекне көчәйтүгә буйсындырыла. Гыйсъянчы лирик герой концепциясенең гражданлык лирикасы кысаларында активлашуы һәм шуның белән янәшәдә фикер-идеянең символ аша җиткерелү сыйфатының көчәюе, экспрессионизмга хас поэтик алымнарның реалистик материалда кулланылышы әлеге жанрның классик булмаган парадигмада үсешен тагын да актуальләштерә. XX гасыр ахыры – XXI гасыр чигендә формалашкан әлеге күренешнең яңа гасырның икенче унъеллыгында да дәвам ителүе татар шигъриятендә аның традиция булып формалаша баруын дәлилли.

Мондый шигырьләрдә төп алымнарның берсе булып демифологизация аерылып чыга. Мифны җимерү сыйфаты эчтәлек катламында гына калмыйча, поэтик яссылыкта да күзәтелә: совет чоры сүз сәнгатендә мифлаштыру максатыннан файдаланылган ил, әләм, көрәшче образларын постсовет чоры шигърияте капма-каршы – демифологик функциядә куллана башлый. Мондый юнәлештәге шигъри әсәрләрдә, гомумән, ил, көрәшче, коммунизм, юлбашчы образлары сәяси эчтәлекле мифологик вазифасын югалта. Мисалларга мөрәҗәгать итсәк, З. Мансуровның «Чүп-чар тавы» шигырендә татар шигърияте тарихыннан мәгълүматлы укучы өчен әләм, ил образларының кулланылышы бәяне сәяси яссылыкка күчерә. Шагыйрь әхлакый кыйммәтләр янәшәсендә сәяси кыйммәтләрнең дә югалуы, ялган идеалларның да җимерелүе хакында сөйли башлый. Ф. Мөслимованың «Патша белми» (2017), Ф. Җамалетдинованың «Сүз калган» (2017), Л. Леронның «Өзеклек» (2017) кебек шигырьләре дә мифны җимерү алымына йөз тотып языла һәм совет, постсовет чоры идеалларын бәяләүгә яки кире кагуга юнәлтелә.

Илдәге вазгыять, көнкүреш, иҗтимагый барышка бәя биреп язылган иҗат җимешләрендә җәмгыяткә бәянең, милли хәл-халәткә мөнәсәбәтнең метафора-символлар, эзоп теле аша ачылу традициясе дәвам итә, үстерелә. Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Корбан, Г. Морат, Р. Низами, И. Гыйләҗев, Н. Әхмәдиев, Г. Морат, урта һәм яшь буын авторлардан Р. Сәләхов, Р. Мөхәммәтшин, Ф. Гыйләҗев һ.б. шигъри әсәрләрендә икенчел эчтәлек тудыру алымы ачык күренә. Бу күренеш үзе үк хәзерге татар поэзиясендә эзоп теле алымының кабат актуальләшүен, лирик герой кичерешләрен яки автор позициясен җиткерү барышында алга чыгуын дәлилли. Гомумәдәби фонда «яшерен эчтәлек» алымының кабат яңаруы шигъриятнең «үз» традицияләренә әйләнеп кайтуы кебек кабул ителә, чөнки милли әдәбият өчен икенчел эчтәлек тудыру алымы традицион. Мәсәлән, Г. Моратның «Әкиятне башлыйк яңабаштан» (2014) шигырендә әкият бүгенге яшәешне, милләткә мөнәсәбәтне бәяләү барышында кулланылган метафора вазифасын үтәп, икенчел планда төрле эчтәлектәге иҗтимагый лозунгларның әкият булуын ассызыклый. Шигырь структурасында әкият яшәешне бәяләү барышында кулланылган метафора вазифасын үти, халык язмышын, бүгенге һәм киләчәк турындагы шагыйрь уйлануларын җиткерүче булып төгәлләшә. Әкияттәге бармагын кыскан Шүрәлене иректә итеп күрү теләге, әфсенгә тарыган Ак бүренең әфсенен кире кайтару омтылышы, Аркадашлары чокыр казыган Турай батырны коткару, Сак белән Сокны кавыштыру хыялы һ.б. аркылы әдип Яңа яшәеш сурәтен төзи; шартлы алым – әкиятне һәм чынбарлыкны кушу аша мифологик үткәнне һәм бүгенгене бер ноктага җыя, яшәешкә, җәмгыятьтәге тәртипләргә фәлсәфи бәя-мөнәсәбәт белдерергә омтыла. Әкияткә хас аерым сыйфатлар кеше тормышына үрнәк итеп күтәрелә.

Р. Сәләховның «Таш өстендә үскән куаклар» (2012) шигыре дә шушы традицияләрне дәвам итеп языла. Бер караганда шигырьдә

идеологик укыла торган яки идеологик эчтәлеккә ишарә ясаган образлар юк. Әмма шигырь тукымасында кабатлана килгән «таш өстендә үскән куак» образы, кабатлау алымы аша, символик югарылыкка күтәрелә. Шуңа мөнәсәбәттә куак / кеше, таш / иҗтимагый вазгыять янәшәлекләре пәйда була һәм яшерен эчтәлекне ачарга ярдәм итә: горур калганда, яшәүгә өметне җуймаганда, алга таба яшәргә көч табып була! Шушы ук фикер символик эчтәлек аша милләт язмышына бәйле дә аңлашыла ала. Р. Харисның «Беренче хәбәр» (2013), «Елатмаска иде бәбиләрне» (2013), «Учым» (2012), «Курыкмыйча яшик» (2013), Ф. Дәүләтбаевның «Тормышта да шахматтагы кебек», «Бутамагыз мине», «Караңгылыкта», М. Кәримовның «Булабыз», «Искә алу» Р. Корбанның «Тукран» (2014) һ.б. шигырьләрдә дә әлеге үзенчәлекләр үстерелә.

Эзоп теле алымы милли тема-проблемаларга йөз тоткан әсәрләрдә дә актуаль булып кала. Мондый шигъри үрнәкләрдә, кагыйдә буларак, татар милләтенең киләчәге, татар теленең язмышы, аның тормыштагы урыны, роле, милли битарафлык, ваемсызлык мәсьәләләре әйдәп бара. Соңгы елларда аваздаш эчтәлектәге әсәрләр аеруча Р. Фәйзуллин, А. Хәлим, Г. Рәхим, Р. Вәлиев, З. Мансуров, М. Мирза, Р. Шәрипов, Ф. Дәүләтбаев, Р. Бәшәр, Т. Шәмсуаров, И. Гыйләҗев, Р. Идиятуллин, Ә. Гаффар, Х. Бәдигый, Н. Әхмәдиев, Р. Сафин, Ф. Гыйләҗев, А. Суфиянов, Р. Сүлти, Ф. Зыятдинов, Р. Мөхәммәтшин, хатын-кыз шагыйрәләрдән Н. Сафина, Л. Шагыйрьҗан, Э. Шәрифуллина, Ф. Гыйззәтуллина, С. Гәрәева, Ф. Тарханова, Р. Шаһиева, И. Иксанова, Г. Әхтәмова, Ф. Җамалетдинова һ.б. иҗатларында урын ала. Мәсәлән, Н. Әхмәдиевнең «Ыру башы – Ак бүре» шигырендә Г. Тукайның «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» гыйбарәсе эпиграф итеп алынып, шигырь шул сорауга җавап төсендә язылган. Ак бүре метафорасы шигырь структурасында милләткә бәя бирү функциясен беркетә. Аның батырлыгы, ыру саклау сәләте татар менталитетын, ак бүре / капкындагы соры бүре оппозициясе татарның холкын һәм бүгенге хәл-халәтен бәяләүгә юнәлтелә. Татарда ак бүре сыйфатларының җиңеп чыгачагына ышаныч идея булып укыла.

Милли темага язылган аерым шигырьләр романтик материалда реалистик әсәрләргә хас иҗтимагый детерминация күренешенең булуын дәллилли. Татар шигъриятендә романтизмның мондый трансформациясе 1970-80 еллардан башланып, постромантизмның формалашуына алып килә. Бу күренеш узган гасыр ахырында Ф. Сафин иҗатында калку чагылыш таба [Загидуллина, 2017, с. 121]. XX-XXI гасыр чикләрендә ул тагын да активлаша. Мисал өчен, Р. Бәшәрнең эзоп теле алымына таянып язылган «Мираж» шигырендә дә метафорик сурәтлелек ярдәмендә милләт язмышына бәя бирелә, яшерен эчтәлек алымы әсәрдән яңа мәгънәләрне табарга мөмкинлек бирә. Мираж / төш каршылыгы шигырь структурасында чынбарлык / хыял булып тәгәлләшә, миражга хас сусыз, эссе чүл, шомлы ил, шәүлә, әләмсез, адәмсез ил метафора, эпитетлары татар милләтенең бүгенге халәтен ачуга буйсындырыла. Татар укучысына Дәрдемәнд иҗатыннан яхшы таныш булган искән җил, тузгытылган комнар һәм ком таулары күмгән юллар кебек символик образлар шигырь кысаларында кылган гамәлләрнең, үткән елларның мәгънәсезлеге, эзсез үтүе мотивын яңарта һәм лирик герой күңелендә әрнү тудыра. Оппозицион вариантта бирелгән төштәге азан моңы, бәхетле кешеләр, җәннәт тормышы кебек образ-детальләр исә лирик геройның милләт киләчәге хакындагы хыялы булып тәгәлләшә. Шигырь тукымасыннан милләтне шушы хыял яшәтә дигән фикер саркып чыга.

Р. Фәйзуллинның хронотопка бәйле төстә шартлы өч өлешкә бүленгән «Китә казлар...» (2014) шигыре дә татар халкы язмышының төрле борылышларын бәяли. Милли поэзиядә авыр язмышны, аерылу сагышын гәүдәләндереп килгән традицион каз образын шагыйрь яңа мәгънә белән баета һәм сәяси, идеологик эчтәлектә укучыга тәкъдим итә. Шигырьнең беренче өлешендәге Донбасска киткән казлар шигырь тукымасында төрле кыйтгаларга таралган, сибелгән һәм үз нигез тамырларыннан аерылган татар язмышына ишарә ясый. Лирик геройның әрнүе дә аларның бүгенге тормыш-көнитешенә бәйләп куела һәм шигырьне сәяси мотивларга баета. Әсәрнең икенче өлешендә гәүдәләнгән Иделгә китеп баручы казлар, үз төбәгендә гомер үткәреп тә, аяныч яшәешкә дучар ителгән татар язмышын танырга мөмкинлек бирә. Шигырьнең өченче өлешендә кайтып баручы казлар автор позициясен җиткерү функциясен ала. Лирик геройның әрнүе татар авылларының бетүе, буыннар өзелү белән бәйләп куела. Соңгы өлештә бирелгән рәшә образы, традицион символик эчтәлек белән өретелеп, автор өметләренең булмавын ассызыклый.

Мондый юнәлештәге аерым шигырьләр интертекстуальлек алымына таянып языла. Мәсәлән, Л. Шәехнең «Тулгак тота мине...» шигырендә лирик герой халәте «тулгак тоту» гыйбарәсе аша җиткерелә, Г. Афзал иҗаты белән интертекстуаль бәйләнешләр ярдәмендә тирәнәйтелә. Р. Зәйдулла иҗатында да Дәрдемәнднең символик үрнәкләренә хас традицияләрнең дәвам ителүе күзгә ташлана, хәтта шагыйрьнең аерым шигъри юллары интертекст буларак та урын ала, «Татар шагыйрьләре китә» шигырендә «Туй гөрли дөньяда соңгы / Без монда кияү түгел» юллары Дәрдемәнд иҗаты белән ассоциация уята. «Кирмән» шигырендә кирмән, чәнечкеле гөлләр, үксез кош образлары бүгенге вазгыять шартларындагы милләт яшәешен шәрехләргә мөмкинлек бирә. Р. Вәлиевнең «Яңа елның яңа таңы ата» (2016), С. Әхмәтҗанованың «Давыл», «Йоклар әле бу ил чак кына...», Р. Мөхәммәтшинның «Әлли-бәлли-бәү» (2016) шигырьләрендә дә интертекстуальлек алымы кулланыла. Шушы дулкында XX йөз башыннан кулланылышта булган йокы мотивы активлаша һәм традицион төстә милли эчтәлектә калыплашып, милләтнең битарафлыгын, гамьсезлеген ачуга юнәлтелә.

Милли юнәлештә иҗат ителгән әсәрләрдә авыл, туган нигез образлары, гореф-гадәтләргә бәйле сурәтләр калка, фольклордан үстерелә килгән образ-детальләр активлаша. Мисал өчен Г. Мөхәммәтшинның «Авылыма мәдхия», «Туган як», «Юлчыга», Г. Рәхимнең «Бәрәңге кәлҗемәсе», Р. Газизовның «Көтә гармун», Р. Бәшәрнең «Тургай» кебек шигырьләрендә, Ф. Тарханованың «Капка» циклында туган як, туган авыл, балачак, әти-әни сурәте тергезелә. Әлеге үрнәкләр, гомумәдәби фонда, XX гасырның икенче яртысы татар поэзиясендә үсеш алган салмак лирика агымының дәвамы кебек кабул ителә. Халык авыз иҗаты белән бәйләнешнең көчәюе, туган җир, туган нигез, ата-баба җире, туган туфрак, ватан, нәсел-ыру кебек милли яшәешкә бәйле төшенчәләргә игътибар арту татар авылы язмышы хакында уйлану мотивының тирәнәюенә китерә. Мондый шигырьләр, кагыйдә буларак, күп катламга ия түгел, аларда субъектив эчтәлек яшерелми, гади-гадәти поэтик сөйләм алга чыга. Шул традицияләрне үстереп, шагыйрьләр асыл ышанычны, рухи кыйбланы туган ягында, авыл кешесенең яшәү рәвешендә таба, авыл мохитен, яшәешен югары күтәрә, шигырьдәге образлардан башлап, вак детальләргә кадәр шушы максатка буйсындырыла, туган туфракны ярату, җирсү хисе үзәккә куела. Шуның белән янәшәдә туган авыл, гомумән, авылларның киләчәк язмышы өчен эчке сызлану да күзгә ташлана. Мәсәлән, Ф. Тарханованың «Капка» (2016) әсәрендә әти-әни янәшәсендә балачакта калган бәхетле көннәрне искә төшерү якты моң һәм сагыш уята. Капка образы әсәр структурасында уйнатылып, гади капка келәсе образыннан үстерелеп китеп, күңел капкасы, хәтер капкасы, бәхет капкасы, әхлакый идеаллар дөньясына капка кебек мәгънә чикләрендә укыла:

Мин боларны күрше эргәсеннән
Уелыплар төшеп тыңладым.
Түзалмадым: ятим өебезнең
Инде кыйшык капкасыннан кереп,
Баскычына ятып еладым [Тарханова, б. 99].

Постреалистик дулкында язылган әсәрләр гражданлык лирикасына үзгәрешләр алып килә башлый, мондый үрнәкләр гражданлык позициясен иҗтимагый фәлсәфә белән ныгыта. 1990 еллар шигъриятендәге милләт бәхете өчен көрәшкә күтәрелгән, милли җанлы лирик герой тибы яңа гасырда да яшәвен дәвам итә, әмма яңа төсмерләр белән байый. Бу герой гражданлык лирикасы чикләрендә татар халкының тарихи урынын билгеләү яки эзләү белән генә мавыгып калмый, гражданлык позициясе белән яшәү мәгънәсе, яшәешнең фанилыгы хакындагы фәлсәфә чигендә милләтенең мәңгелектәге эзе, кыйммәте хакында фикер йөртә башлый, бу исә фәлсәфи тенденциянең көчәюенә китерә. Мисал өчен М. Галиевның «Чыдам тау да, үзән дә без» (2014) шигырендә ул шулай. Татарның үткәне / бүгенгесе оппозициясенә корылып иҗат ителгән шигырьдә балбал, бөркет, дала, тау, үзән, каганат кебек метафорик-символик образ-детальләр татарның шанлы тарихын сурәтләү юлында файдаланыла. Бүгенге халәтне тасвирлау барышында кулланылган әрнеп үскән әрем образы авторның матур табышы буларак кабул ителә һәм татар халкы язмышының ачылыгын да, хокуксызлыгын да, лирик геройның әрнүен дә үзенә сыйдыра. Шигырьнең соңгы юллары автор позициясе булып укыла:

Кайтавазлар иңри, юашланып:
Бүгеннән без, бәлки, бөгелмәбез [Галиев, 2014, б. 68].

«Су каргышы» (2015) циклында М. Галиев милли тема-проблематиканы мотивлаштырылган су образы аша ачуга ирешә. Су язмышы

вакытлар агышын да, татар халкының бай тарихын, болганчык язмышын да, данлы һәм шанлы вакытларының үтүен дә символлаштыра. Үзенчәлекле яңгырашка корылган әсәр үзе чәчмә һәм тезмә жанр формаларының синтезы төсендә уйланылган. Циклның башындагы «Бәгырь авазы»нда ук башланып, әсәрнең үзәгенә куелган «Барыберме сезгә? Барыберме безгә?» соравы кабатланып, әсәрне тотып торучы композицион принцип ролен үтәве белән янәшәдә, авторның идеясен үткәрүдә үзәк вазифаны башкара. Ул идея милләтнең бүгенге халәтенә, киләчәк яшәешенә барып тоташа һәм автор фикерен кабатлый:

Үчләшсеннәр, көнләшсеннәр, үлчәшсеннәр,
Булганбыз ла! Булабыз да! Булачакбыз!
Мең елдан да татар булып туачакбыз!

[Галиев, 2018, б. 158].

Р. Мөхәммәтшинның постреалистик дулкында язылган «Казан» (2007), «Гасыр башы» (2012), «Бүрелек» (2013) кебек шигырьләре дә милләтнең бүгенге халәтенә, битарафлыгына сызлану булып кабул ителә. Б. Ибраһимов «Балык теле» шигырендә милли вазгыятьне, тел югалу проблемасын балык теле образы аша җиткерә. Балык теле күпмәгънәле символ телнең югалуын, кешеләрнең телсезгә әйләнүен аңларга мөмкинлек бирә, шуның ярдәмендә җәмгыятьтәге милли проблеманы күтәреп чыга. «Без» исеменнән сөйләү әлеге проблеманы «татар» контекстыннан алып чыгып китә, гомуми проблемаларның берсенә әйләндерә.

Мондый эзләнүләр әкренләп гражданлык лирикасында лирик герой концепциясен үзгәртә. Бу яңарыш лирик герой – милләт чылбырында үзен милләтнең бер баласы итеп тойган, «мин» исеменнән сөйләгән лирик геройны калкуландыра, аның халәте исә реалистик чикләрдән чыгып китеп, постмодерн алымнар ярдәмендә ачыла башлый. Бу исә лирик геройның статусы үзгәрешенә алып килә: бер яктан, аның милләт язмышы өчен шәхси җаваплылык тойгысы артса, икенче яктан, милли проблемаларны «читтән», объектив бәяләү мөмкинлеге туа. Лирик герой, хәзерге рус постмодернистик шигъриятендәге кебек үк, «шигырь язучы кеше»гә [Современная русская..., с. 109] әверелә. Д.Ф. Заһидуллина татар әдәбиятында модернизмның гына түгел, постмодернизмның да югары эмоциональлеккә, тәэсирлелеккә омтылуын күрсәтә [Загидуллина, 2017, с. 94]. Бу күренеш лирик герой концепциясен дә читләтеп үтми, кеше язмышы – милләт язмышы чылбырында «шәхсиләшү» көчле булып кала. Мәсәлән, Р. Аймәтнең «Гөлләр чагым эзлим» (2002) шигырендә милли вазгыятькә бәйле лирик герой кичерешләре алга куела, «мин» исеменнән сөйләгән лирик герой йокыга талган милләт халәтеннән гаҗизлек хәленә килә, бу халәт риторик эндәшләр аша көчәйтелә.

Авааздаш мотивлар Л. Гыйбадуллинаның «Минем канда хәтер исән!» шигырендә дә урын ала. Озын шигырь формасында язылган әлеге әсәрдә «мин» исеменнән сөйләүче лирик геройның милләт язмышы хакында уйланулары гәүдәләнә. Шушы фонда хәтернең кеше – милләт чылбырында хәлиткеч мөһим бер элемент, әһәмиятле буын булуы раслана.

Мондый шигырьләрдә интертекстуаль бәйләнешләр, янәшәлекләр зур урын тота, яңа мәгънәләр табуга юнәлтелгән катлаулы образларны, детальләрне тезеп барып, ассоциатив сурәтлелек тудырыла, тәэсирлелек көчәйтелә, сызлану халәте үзе дә постмодернистик алымнар, интертекст базасын формалаштыруга кушылып китә. Мәсәлән, Б. Ибраһимовның «Бу көннәрдә мин дә яза алмыйм» (2017) шигырендә иллюзиялелек күренеше лирик геройның яңа статуска күтәрелүе аша чагылыш таба. Г. Бәйрәмова «Шигырь сатам...» (2017) шигырендә интертекстуальлек алымына мөрәҗәгать итеп, «шигырь сатам, шигырь, кем ала?» юлларында билгеле гыйбарәне уйната, аны текст эчендә кабатлау исә сүз кадере беткән бу заманда шигъриятнең үксез-ятим бала хәлендә калуын, кадерсез булуын искәртә. Л. Янсуарның «Югыйсә» (2017) шигырендә типик мозаик сурәтлелек урнаштырыла: тынлыкның түреннән Иделне кубарып җил исә, Актырнак өрүе ишетелә, көтү куыла, шулар янәшәсендә ил сурәте калка, тузганак таҗларын, шашынган карларны күрәү турында сүз башлана. Әлеге фрагментар, аерым-аерым тезелгән детальләр автор фикерен җиткерүгә юнәлтелә. Бер карашка бер-берсенә бәйләнешсез сурәтләр милләтнең зурдан кубып, вак эшләр белән шөгыльләнүе, шулардан зур мәгънә эзләве, системалылык булмау турында сөйли. Милләт хәтере генә безне туры юлга ирештерә алачак! – дип дәшә шагыйрә.

Классик романтизм кысаларында иҗат ителгән шигъри әсәрләр, нигездә, яшәеш кыйммәтләрен аңлау-анализлауга йөз тота, аларда фәлсәфи гомумиләштерүләр ясау омтылышы көчле. Бу юнәлеш традицион төстә күңел лирикасы һәм фәлсәфи лирика жанрларына яратып мөрәҗәгать итә, авыр кичерешләрдән

юануны балачактан, авылда үткән яшьлек сукмакларыннан, мәхәббәттән, туган як җылысыннан эзләгән эмоциональ лирик герой үстерелә һәм поэзияне лирик-эмоциональ, вакыты белән сентименталь дулкынга көйли. Бу юнәлештә Р. Гаташ, Р. Вәлиев иҗаты әйдәп бара. Хатын-кыз шагыйрәләр иҗатында К. Булатова, Р. Рахман, Ф. Җамалетдинова, И. Иксанова, Х. Мөдәррисова, С. Якупова, урта һәм яшь буын шагыйрәләрдән Л. Янсуар, Л. Гыйбадуллина, Г. Корбанова, Л. Вәлиева h.б. шул юнәлештәге шигырьләре уңышлы кабул ителә.

Романтик юнәлештәге аерым әсәрләрдә еш кына көнчыгыш әдәби сурәтләре шигырь структурасына уңышлы кертеп урнаштырыла, суфичылык яки фольклор әсәрләренә охшатып стильләштерү дә күзгә ташлана, романтик әсәрләрнең фәлсәфи яктан баюы күренә. Мондый сыйфат белән без Р. Зәйдулланың «Фәрештә», «Төрек кызы», «Күрән», М. Галиевнең «Төштән – төшкә», К. Булатованың «Һәр Мәҗнүннең үз Ләйләсе була» h.б. шигырьләрдә дә очрашабыз.

Бер төркем шигырьләр традицион романтик сурәтлелеккә йөз тота, мондый әсәрләр фольклордан үстерелә килгән романтик янәшәлекләргә мөрәҗәгать итеп языла. Мисал өчен Р. Фәйзуллинның күчмә утрау / утрак җир каршылыгына корылган «Күчмә утраулар» шигырендә Аккошта, Кабанда булган утраулар образы метафора булып килә. Шушы фонда тормыш, яшәү елгасында очраган күчмә утраулар мәхәббәт тарихлары булып тәгәлләшә. Гомер юлында кичерелгән мәхәббәт кеше күңелендә онытылмый, гомер буе саклана дигән фикер автор идеясе кебек тәгәлләшә.

Романтик юнәлештә язылган әсәрләрдә фәлсәфи мотивларның көчәюе күзгә ташлана, бу исә романтик лирик герой концепциясенең яңа чалымнар белән баюына китерә: ул философ лирик герой булып, яшәү һәм үлем, яшәү мәгънәсе, кеше гомеренең кыйммәте, кеше һәм табигать бәйләнешләре, гомумән, яшәешнең асылы турында уйлана; мәхәббәткә, туган җиргә, якыннарга мөнәсәбәтле хис-кичерешләр дә фәлсәфи эчтәлек белән өретелә. Шуңа да мондый шигырьләрнең үзәгендә уйланучан, яшәешнең асылына төшенергә омтылучы лирик герой тора, ул тормышны яшәү һәм үлем бөтенлеге рәвешендә күзаллый, хакыйкать темасын үз итә, фәлсәфи гомумиләштерүләре белән уртаклаша. Шушы юлда үз сорауларына җавап эзли, икеләнә, хакыйкатьне төрле ноктадан килеп эзләп, аңлатып-шәрехләп карый. Бу үзгәреш, үз чиратында, заман шагыйрьләренә фәлсәфи тирәнлектә фикер йөртү һәм формага бәйле тәҗрибәләр, экспериментлар ясау, шулар аша катлаулы сурәт тудыру өчен яңа мөмкинлекләр ача. Бу үзенчәлекләр Н. Гамбәр шигырьләрендә актив. Лирикасындагы бер төркем шигырьләрнең үзәгенә кеше фәлсәфәсе куела, яшәешнең асылы, мәгънәсе, кеше гомере, аның миссиясе хакында уйланулар үзәк лейтмотивны тәшкил итә. Үз сорауларына җавап эзләү, яшәүнең асылын танып белергә омтылу юлында шагыйрь еш кына кеше гомеренең төрле этапларын тергезергә ярата. Мондый шигырьләрдә Наис Гамбәр табигать күренешләренә, ел фасылларына, тәүлекнең төн һәм көн вакытына, төсләргә аеруча игътибарлы, аларның һәркайсы фәлсәфи гомумиләштерүгә ия. Мисал өчен, «Көз – моңлы күз» шигырендә беренче строфа ук әсәрне кеше фәлсәфәсенә кора. Көз образы белән янәшә килгән моңлы күз, айныган бал, җам образлары аны табигать чикләреннән алып чыгып китә.

Көзнең күзендә уйчан моң бар,
Яшерен сабырлык бар җанында;
Күпреп, кайнап торган хисләр түгел,
Айныган бал инде җамында [Гамбәр, б. 30].

Суфичылык поэзиясеннән танылa торган традицион образларга мөрәҗәгать аша укучы сүзнең мәхәббәт хакында барганлыгын ачык тоемлый. Җамнан бал эчеп исерү суфиларда илаhи мәхәббәт мотивын тергезсә, әлеге шигырь кысаларында сүнгән-сүрелгән дөньяви мәхәббәт эчтәлеген яңарта. Автор кеше яшәешенә хас канунны кабатлый: бар да вакытлыча, бар да фани, яшьлек тә, гомер дә, мәхәббәт тә үтә. Икенче строфадагы көз образы табигатькә ишарә ясый, торналар китүе, үләннәр саргаюы, көзге табигатьтәге сарылык, таллар муенына сарылып су өстеннән аккан пәрәвезләр – барысы да табигатьтәге моңсу халәтне җиткерүгә буйсындырыла. Шигырьнең буеннан-буена кеше гомере белән табигать күренешләре бер бәйләмдә сурәтләнә, шуның аша автор яшәештә генә түгел, табигатьнең үзендә дә һәр нәрсә ялгыз, вакытлы, үтә-югала, дип кабатлый.

Наис Гамбәрнең лирик герое яшәү мәгънәсен эзләү барышында еш кына «яшәүдән соң яшәү бармы?» соравына җавап эзли. Мәсәлән, «Кабатлана...» шигырендә кешенең «яна, яна китеп баруы» сызлануның сәбәбе булып тәгәлләшә. Шушы сызланудан котылу чарасын эзләп, лирик герой яшәүдән соңгы

яшәеш хакында уйлана, табигать фасылларының кабатланышы, орлыклардан шытып чыккан гөлләр аша табигатьтә яңарыш барлыгын дәлилли. Кабер өстендә үскән резедалар, интертекстуальлек алымы аша Х. Туфан шигыре белән тоташып, аваздаш ассоциация тудыра, кешедән соң якты хатирәләр яшәвенә, кешенең яңа буыннар күңелендә тергезелүенә йөз тота. Табигатьтә кабатлану мөмкин, ә кеше тормышы кабатланмый, әмма хатирәләрдә яшәү мөмкин! Автор үз укучысына шушы фикерне хакыйкать төсендә җиткерә. Буыннар хәтерендә саклану мөмкинлеге кешене табигатьтән, яшәешнең башка өлкәләреннән аерып торган бер сыйфат дәрәҗәсенә күтәрелә.

Хәзерге татар поэзиясе яңа экспериментлар ясау мәйданына да әверелә. Әлеге яңарыш, иң беренче чиратта, татар шигъриятендә лирик герой концепциясенең үзгәрүеннән һәм дөнья сурәтенең алмашынуыннан башланып китә. Р. Зәйдулла, Р. Аймәт, Й. Миңнуллина, Б. Ибраһимов, Р. Мөхәммәтшин, Л. Гыйбадуллина һ.б. шигырьләрендә эзләнүләр аеруча көчле булып тоела.

Классик булмаган дөнья сурәтендәге хаотик тормышта ачыклык таба алмаган лирик геройның аң-фикер агышы Зөлфәт иҗатыннан үсеп китә. «Ил халәте» (2001), «Безнең чор агайлары» (2002), «Каргыш» (2003), «Болгавыр» (2005), «Караңгы төнге җилләр» (2002), «Аймылыш» (2002), «Талсиртмәдә талбишек» (2002), «Читән күләгәсе» (2003), «Ялган ямь» (2004), «Соңгы язмыш яры» (2003), «Кое кибә...» (2006) кебек җәмгыятьтәге хаксызлыклар хакында сөйләгән шигырьләрендә әдип лирик геройның тәртипсез, бер-берсен еш алыштырып килгән хис-кичерешләр дулкынын сурәтләү объекты итеп күтәрә. Әлеге хис-кичерешләр дулкыны, яшәешкә генә түгел, иҗтимагый-сәяси тәртипләргә мөнәсәбәтле дә ачылып китә, символик образлар кулланылышы шигырьне төрле катламнарда кабул итү мөмкинлеген бирә. Хаотик тормыш-яшәештә, дисгармоник тормышта өметләрнең акланмавын тойган лирик герой чарасызлык, үкенеч, фаҗига, югалу дулкынында сурәтләнә, ялгызак шәхескә әверелә. Еш кына ул кайгы, чарасызлыктан туган сызлану чигеннән битарафлыкка күчә яисә сагыш аша шатлыкка омтыла. Әлеге халәт әсәрләр структурасында монолог, төш, еш алышынган күзаллаулар, символик образ-детальләр аша җиткерелә.

Алга таба бу тип лирик герой Л. Зөлкарнәй тарафыннан үстерелеп китә. Әмма Зөлфәт шигырьләрендә хаотик халәт еш кына җәмгыятьтәге, лирик геройны әйләндереп алган тышкы дөньядагы яисә милләт яшәешендәге хәл-халәткә мөнәсәбәтле булса, Л. Зөлкарнәй шигырьләрендә инде ул геройның үз эчке дөньясындагы, фикер-күзаллауларындагы үзгәрешләргә бәйле формалаша. Бу үзенчәлек татар шигъриятендә яңа сүз булып яңгырый. Л. Зөлкарнәй шигырьләрендә лирик геройның уй-фикерләре тоташ рефлексия төсен ала, аның хаотик халәттәге аң агышы импрессионистик алымнар ярдәмендә җиткерелә. Әлеге тип лирик герой урын алган шигырьләр еш кына Ш. Анак тарафыннан яратып кулланылган сөйләм шигыре формасында иҗат ителә. Мисал өчен, Л. Зөлкарнәйнең «Монолог» шигырендә лирик герой халәте шигырьнең исеме – көчле позиция аша ук төгәлләштереп куела, хаотик кичерешләр монолог төсендә җиткерелә:

Көйсез көнем, тезләреңне кочып утыр,
ә мин бием, бием бүген егылганчы,
бием менә елый-елый!
...
Үзең эндәшмәсәң,
беркем күрми,
үпми... [Зөлкарнәй, б. 290].

Саташулы, нәфрәтле халәттәге лирик герой яшәештәге күренешләрне үзгәртә алмаудан гаҗизлек баскычына килә. Лирик герой халәте туктаусыз әйләнгән, өзлексез хәрәкәттә булган Җир, иске тәлинкә образлары ярдәмендә ачыла, иске тәлинкә лирик геройның психологик яше белән биологик яше арасындагы аерманы да җиткерә. Шигырь ахырда үз чарасызлыгын аңлаган лирик геройның шушы халәте өчен әйләнә-тирәдәгеләрдән гафу үтенүе белән каймап алына.

Әлеге тип лирик герой алга таба Сөләйман, Р. Аймәт, Л. Гыйбадуллина шигъриятендә дәвам итә. Сөләйманның лирик героенда, гомумән, хис-кичерешләрнең хаотик тәртибе, эзлексезлек, бер чиктән капма-каршы булган икенчесенә ташлану сыйфаты көчле:

| | |
|---|---|
| Ап-ачык,<br>Ап-ак,<br>Яп-якты –<br>Әҗәл.<br>Буталчык,<br>Кап-кара, | Караңгы –<br>Яшәү.<br>Гомер буе тартылабыз<br>Ачыклыкка,<br>Аклыкка,<br>Яктылыкка<br>[Сөләйман, б. 109]. |

Р. Аймәт шигырьләрендә дә хаотик яшәештәге лирик герой халәте аң агышы ярдәмендә сурәтләнә. Дисгармоник яшәештә бәхет тапмаган лирик герой, бу халәт-яшәешне

үзгәртә алмавын аңлап, кешеләрдән читләшә («Мин җирләргә төштем», 2001), хыял дөньясына юл ала («Эзләмәгез мине», 2000).

Постмодерн эзләнүләр әкренләп шәхес концепциясеннән поэтик яссылыкка күчә бара. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, мондый әсәрләрдә дөньяны, яшәешне катлаулы бербөтен, театраль тамаша итеп сурәтләргә омтылу, җемелдәү эстетикасы (мотивларның җемелдәп алуы), күпъяклылык һәм фрагментарлык күренешләре урын ала [Загидуллина, 2017, с. 190].

Әлеге алымнар белән Л. Гыйбадуллина шигырьләрендә очрашабыз. Мәсәлән, «Бер карышка – бер җан, бер карышка – мөлдерәмә тулы мизгел бары» башламы астына тупланган шигырьләргә кабатлау эстетикасы хас, бер үк элементларны, образларны кабатлау яңа мәгънә бөтенлекләренә алып чыга, иллюзияле сурәтлелек, эзлекле, төзек композициядән китү сыйфаты күренә. Шагыйрәнең шигъри теле образлы, ул киң кулланылыштагы образларны яңа мәгънәви бөтенлекләренә алып чыга, бербересенә тәңгәлләшмәгән образларны янәшә куеп, образларның мәгънәви чикләрен киңәйтә. Нәкъ шушы сыйфатлар төрле баскычтагы мәхәббәт тойгысын – илаһи мәхәббәтне, сөйгән ярга мәхәббәтне, милләткә мәхәббәтне сурәтләргә мөмкинлек бирә. Шушы мизгелләрне бер карышка җыя алган кеше җаны югары күтәрелә. Шушы ук үзенчәлек «Бу гавам сагыштан яралган» шигырендә дә күзгә ташлана, ак, кара образларын кабатлау төрле мәгънә бөтенлекләренә алып чыгарлык итеп корыла, яшәештәге һәр кыйммәтнең иллюзия булуы дәлилләнә.

Лириклык һәм символик сурәтлелеккә, детальләштерүгә, интертекстуаль бәйләнешләргә омтылыш Й. Миңнуллина иҗатының да үзәгендә тора. Шигырьләренең исемнәре үк көчле позициядә аерым фрагментлардан җыелган мәгънәне төгәлләштереп бара. Шул ук вакытта шигырь исемнәрендә асмәгънәгә ишарә ясала, һәм еш кына шул исем әсәр структурасына яшеренгән доминанта мәгънәне төгәләштереп куя. Мисал өчен, «Бозлы тәрәзәдә бармак эзе» шигырендә гадәти тормыш картинасы тергезелә: лирик герой шәһәрне күзәтә. Типик мозаик сурәтлелек урнаштырыла: кыш, әби оныгына оекбаш бәйли, мәчет каршында бер ир өеннән төнге шәһәргә чыгып югала. Әлеге фрагментар, аерым-аерым тезелгән детальләр иң соңгы ике юлда автор фикерен формалаштыра:

Тоныклана бара шәһәр...
тының белән җылытмасаң әгәр [Миңнуллина, б. 13].

Автор фикеренчә, һәр кеше үз тирәлеген үзе булдыра, шул тирәлектә яшәү мәгънәсен дә үзе билгели, яшен кебек ялтырап үткән яшәештә үз урынын үзе билгели, бармак эзе әнә шуңа ишарәли.

Э. Байназаровның «Без» (2014) шигырендә дә охшаш образлылык һәм мотив чагылыш таба. Гомумән, бу яшь шагыйрьнең иҗатында образлы сурәтнең көчле булуы күзгә ташлана, ул катлаулы, көтелмәгән янәшәлекләр ярата (мәсәлән, «Кечкенә мәгънәсезлек»), композицион алымнардан сирәк мөрәҗәгать итеңә торган монтаж алымын отышлы куллана. Мәсәлән, «Мүкләнгән диварлар җылысын кызганды» (2014) шигырендә укучы тыгыз сурәтлелек белән очраша, мүкләнгән дивар, бәсләнгән ирен кебек эпитет-метафоралар мәхәббәтнең салкынлыгын җиткерү юлында файдаланыла.

Ассоциатив сурәтлелеккә омтылган әсәрләр Р. Харис иҗатында да урын ала. Мисал өчен, күпкатламлы, күп мәгънәле метафориксимволик сурәтлелеккә корылган, укучының үзенә чишәргә калдырылган шигъри табышмакларны хәтерләткән, әзерлекле укучыга юнәлтелгән «Кара түгәрәк» шигыренә күз ташласак, сәнгати чаралардан көтелмәгән борылышлар, катлаулы чагыштырулар, сынландыру, янәшә кую, бер күренешнең мәгънәсен икенчесеннән табу, өченчесе ярдәмендә ачу – Р. Харисның лирик фикерләү үзенчәлеге – бу шигырьдә дә актуаль булып калуын күрәбез. Шигырьдә Малевичның «Кара квадрат»ындагы сурәтлелек шигъри метафора ролен башкарып, кара, яшел, сары һәм ал сызыклар яшәешне, кеше тормышындагы аерым мизгелләрне бәяләү югарылыгына күтәрелә. Кара / чиксезлек янәшәлеге аша автор мәңгелекне төгәлләштерә, мәңгелек / фани каршылыгының чиген акыл билгели. Шагыйрь фикеренчә, кеше яшәеш дәвамында мәңгелектән килеп, өзлексез төстә, акыл белән танып-белеп булмый торган мәңгелеккә омтыла, шушы омтылыш кеше тормышында түгәрәкне хасил итә. Ассоциатив сурәтлелек аша яшәешкә (җиһан) һәм җир тормышына, кешегә бәя бирү омтылышы Сөләйманның «Татар бишегендә татар баласы», «Канатларны – каурый каләм иттем» кебек шигырьләрендә, «Югалыр күк бу мизгел» шигырьләр бәйләменә тупланган үрнәкләрендә һ.б. көчле чагыла.

Хәзерге татар поэзиясе жанр трансформациясе, яңарышы ягыннан да колачлы,

масштаблы эзләнүләр алып бара. Бу яктан аеруча поэма жанры үзенчәлекле. Бер төркем поэмалар татар поэзиясендә XX йөз башыннан Ф. Кәрим, С. Хәким һ.б. тарафыннан үстерелә килгән традицион стильне дәвам итеп мәйданга чыга. Р. Миңнуллинның «Сөю», Ф. Гыйләҗевнең «Иске Казан – Кирмән нигезе», Р. Вәлиеваның «Яралы язмыш» һ.б. поэмаларда лирик герой хикәяләүче, хис-кичерешне җиткерүче функциясен ала, тегe яки бу тормыш вакыйгасы, мәхәббәт хис-кичерешнең сәбәбенә әверелә. Мәсәлән, Р. Вәлиеваның поэмасында лирик геройның әрнү хисенә Мирхәйдәр белән Гөлнисаның мәхәббәт тарихы, сугыш фаҗигасе сәбәп төсен алса, Р. Миңнуллинның «Сөю юлы» әсәре Сөю, мәхәббәт кичереш сызыгын әсәр буена үстереп бара, кешенең яшәеш юлына хас сыйфатлар мәхәббәткә бәя бирүгә юнәлтелә. М. Мирзаның сугыш темасына язылып, бер гасырлык тарихны үз эченә алган «Кысыр Гариф» поэма-кыйссасы соңгы елларда актуальлеген югалта төшкән сугыш темасына язылган поэмалар рәтен тулыландыруы ягыннан да игътибарга лаек.

Соңгы елларда мәйданга чыккан икенче төркем татар поэмаларының төп хасияте булып төрле катламнарның синтезына омтылыш тора. Катламнарның бергә кушылуына әдәби текстның үз эчендә башка текстлар белән ассоциациясе аша – интертекстуальлек ярдәмендә ирешелә. Мәсәлән, Й. Миңнуллинаның «Өтүкән җирендә ут яна» (2014) поэмасы шундый катламнарның синтезы төсендә иҗат ителгән. Дәүләтчелекне югалту вакыйгалары белән бәйле халык фаҗигасе төрле катламнарның синтезы, интертекст алымнары аша тергезелә. Р. Харис поэмалары интеллектуаль алымнар белән баетылып мәйданга чыга. Аның «Яза башла!» (2017) трактат-поэмасы фәлсәфи эчтәлек белән өретелә, шагыйрь, шигырь, язу гыйбарәләре әсәрнең буеннан-буена уйнатыла, шулар аша төп фәлсәфи фикерләр җиткерелә бара: шигырь намус, әхлак, иман, рухи ныклык, халкыңны ярату кебек иң югары идеаллар хакында булырга, шуларга хезмәт итәргә тиеш. Р. Харисның «Уба» (2017) поэмасы структур яктан төрле катламнарның синтезын тәшкил итә. Ул синтез сәяси-мифологик детальләр, юлбашчы образы аша тергезелгән сәяси-иҗтимагый фикерләрне – идеология һәм кеше язмышы, система китергән фаҗига, халык кичергән фаҗигане, һәм шуңа бәйле туган фәлсәфи мәсьәләләрне – яшәү мәгънәсе, кешелеклелек үрнәге кебек проблемаларны бер әсәр чикләрендә кушарга мөмкинлек бирә. Катламнарның бергә кушылуына әдәби текстның үз эчендә башка текстлар белән ассоциациясе аша – интертекстуальлек ярдәмендә ирешелә. Шагыйрь әсәр тукымасына Сталин турындагы җыр текстларын, сәяси лозунг дәрәҗәсендә кулланылган гыйбарәләрне кертеп урнаштыра, лирик геройның эчке каршылыгын, мифны җимерү алымнарын файдалана. ГУЛАГ төрмәләрендә җәфаланырга мәҗбүр тракторист һәм көндәш авылдашына бәйле сюжет – беренче вакыйгалар катламын гына тәшкил итә. Икенчел ассоциатив катламда шагыйрь шул чор фаҗигасенең кешеләр язмышына тәэсире, ул канлы елларның буыннар хәтерендә саклануы турында сүз башлый. Шуңа бәйле төстә Уба образы да катлаулы символик бөтенлек статусын ала: ул аерым кеше тормышындагы убалардан башлап, ил, тарих чоңгыллары, хәтер төпкелләре, шомлы фаҗигаләр тирәнлеге булып кабул ителә. Ф. Тархановaның «Халкым минем» (2017) триптихы да татар поэзиясенең жанрлык чикләрен киңәйтә. Триптих жанр формасы, гадәттә, уртак идея, фикер тирәсенә өч шигырьне берләштерә. Ф. Тархановaның әсәре дә «Рух вә иман», «Моң», «Тел» кебек өч бүлеккә туплана. Әмма бу бүленешнең эчке логикасы субъектив катламда ачыла һәм әлеге өч төшенчә милләт сагында торучы, татарны татар итүче иң төп сыйфатлар кебек билгеләнә.

Татар поэзиясендә 1990 еллардан соң Р. Гаташ үстереп алып барган традицияләрне дәвам итеп, көнчыгыш шигъри текстларына охшатып стильләштерү, трансформацияләү яки шәркый жанрларны тергезү дәвам итә.

Мәсәлән, Ә. Саттар робагыйлары структур яктан көнчыгыш әдәби традицияләрендәгечә төзелә. Авторның һәр робагыенда, шәркый традицияләргә хас булганча, әхлакый мәсьәләләр үзәккә куела; иҗтимагый-социаль кануннар да фәлсәфи-этик яссылыкта хуплана яки кире кагыла, рухи, әхлакый яңарышка өндәү мотивы көчле яңгыраш ала. Ф. Дәүләтбаевның дүртьюллыклары да, Р. Идиятуллинның «Тормыш» һәм Д. Гарифуллинның дүртьюллыклар бәйләме дә хикмәт һәм робагый жанрларына стилизация буларак кабул ителә.

М. Мирза иҗатында, «Адәм баласы» шигырьләр циклының дәвамы булып, бишьюллыклар жанр формасы кабат мәйданга чыга. Көнчыгыш шигъриятендә киң кулланылган, милли шигърияттә «Туфан строфасы» буларак калыплашкан һәм лирик

герой кичерешен, автор фикерен, текстларның яңгырашын, көен, хисси тәэсирен җиткерүгә йөз тоткан бишьюллыкны М. Мирза бөтенләй үзгә форма итеп төзүгә ирешә. Мәкаль-әйтемнәр куллану, шигырь юлларын хикмәтле сүз әйтү традициясендәгечә төзергә омтылу, үзенә генә хас бик нечкә ирониягә, төртмәле кинаягә мөрәҗәгать итү – барысы да аның үзгәлеген, оригинальлеген тәэмин итә:

Тыелганнан тыела беләбез,
Ана сөте белән күңгәнбез.
Уртак ватан өчен, кирәк икән,
Оҗмахтан тәмугка керәбез, -
Шундый батыр, шундый күндәм без?! [Мирза, б. 20]

Шуңа да алар шәркый бишьюллыкларны стильләштерү кебек түгел, татар шигърияте өчен үзгә жанр формасы буларак кабул ителә.

## Төп нәтиҗәләр

1. XXI гасыр башы шигъриятендә барган эзләнүләр, эчтәлек ягыннан бигрәк, форма һәм шәхес концепциясе бирелешендә көчле булып, төп магистраль юлны саклаган хәлдә, шигъриятне өр-яңа үсеш сукмакларына алып чыга.

2. Реалистик әсәрләрдә тәнкыйди башлангычның көчәюе, милли тематиканың активлыгы, гражданлык позициясенең иҗтимагый фәлсәфә белән баюы күзәтелә. Бу фикер-мотивлар, бер яктан, тормыштагы хаксызлыкны күреп-аңлап та, турыдан-туры каршы чыгарга үзендә көч тапмаган, үз-үзе белән каршылыкта, эчке борчылу халәтендә яшәүче, икенче яктан, дөньяны үзгәртү теләге белән янган, актив тормыш позициясенә ия, гыйсъянчы лирик герой концепциясе аша чагылыш таба. Тәнкыйди бәяне җиткерүдә өч әдәби алым – яшерен эчтәлек, демифологизация һәм интертекстуальлек активлаша.

3. Романтик әсәрләрдә фәлсәфи гомумиләштерүләр, яшәү мәгънәсенә, яшәү кыйммәтенә мөнәсәбәтле уйланулар, дини мотивлар көчле булып кала, шуңа бәйле фәлсәфи лириканың активлашуы, эстетик функциянең көчәюе күренә. Мондый әсәрләрдә лирик герой яшәеш кыйммәтләрен эзләүче философ, бай күңел дөньясына ия эстет булып формалашып җитә. Романтик иҗат үрнәкләре поэтик яссылыкта көнчыгыш символик образ-детальләренең активлыгы, фольклор образларының яңарышы, халык җырларына хас үлчәмнәрдән файдалану, халык җырларына охшатып стильләштерү күренеше белән характерлана.

4. Постреалистик дулкында язылган әсәрләр гражданлык лирикасына үзгәрешләр алып килә, мондый үрнәкләрдә гражданлык позициясенең фәлсәфилек белән кушылуы эчтәлекне тирәнәйтә. Постмодерн алымнарының милли әдәбиятка тирәнрәк үтеп керүе, форма эзләнүләре, лирик герой – милләт чылбырының үзгәреше гражданлык лирикасы үрнәкләрендә лирик герой концепциясен үзгәртә. 1990 еллар шигъриятендә милләт бәхете өчен көрәшкә күтәрелгән, милли җанлы лирик герой тибы кулланылу дәвам итсә дә, чор шигърияте аның яңа модификациясен күтәреп чыга. Бу лирик герой, бер яктан, үз милләтенең бер улы буларак чыгыш ясый, икенче яктан, үзен «аерып куеп», ситуацияне «читтән» бәяләү юлына баса.

5. Постмодернистик эзләнүләр тәртипсез тормышта яктылык тапмаган лирик геройдан башланып китеп, дөньяны, яшәешне катлаулы бербөтен, театраль тамаша итеп сурәтләргә омтылу, җемелдәү эстетикасы (мотивларның җемелдәп алуы), күпъяклылык һәм фрагментарлык, ассоциативлык белән характерлана.

## Йомгак

Димәк, XXI гасыр башы шигърияте форма өлкәсендә җитди эзләнүләр алып барылган чор буларак билгеләнә ала. Әлеге эзләнүләр хаотик тормышта яктылык тапмаган лирик геройдан башланып китә, дөньяны, яшәешне катлаулы бербөтен, театраль тамаша итеп сурәтләргә омтылу, җемелдәү эстетикасы (мотивларның җемелдәп алуы), күпъяклылык һәм фрагментарлык, ассоциативлык белән характерлана. Әнә шулай XXI гасыр башы шигъриятендә барган эзләнүләр, эчтәлек ягыннан бигрәк, форма һәм шәхес концепциясе бирелешендә көчле булып, төп магистраль юлны саклаган хәлдә, шигъриятне өр-яңа үсеш сукмакларына алып чыга.


**Әдәбият**

*Аймәт Р.* Һәрбер мизгеле изге // Казан утлары. 2017. № 12. Б. 76-79.

*Борухов Б.* Введение в мотивирующую поэтику // Филологическая герменевтика и общая стилистика. Тверь: Изд-во Тверского ун-та, 1992. С. 5 - 28

*Галиев М.* Чыдам тау да, үзән дә без // Казан утлары. 2014. № 4. 68 б.

*Галиев М.* Су каргышы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 158 б.

*Гамбәр Н.* Яшәү тамыры. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 351 б.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия рубежа XX-XXI веков (1986 – 2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Фэн, 2017. 268 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская литература XX – нач. XXI в.: «мягкость» модернизма-авангарда-постмодернизма (к постановке проблемы). Казань: ИЯЛИ, 2020. 256 с.

*Зәйдулла Р.* Аваз // Казан утлары. 2017. № 5. Б. 10.

*Зәйдулла Р.* Юл // Казан утлары. 2017. № 5. Б. 6.

*Зөлкарнәй Л.* Мәңгелектән исә җил... Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 290 б.

*Миңнуллина Й.* Күк тирмәсе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 47 б.

*Мирза М.* Берүземә бер диңгез. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 222 б.

Современная русская литература (1990-е гг. – начало XXI в.). / С.И. Тимина, В.Е. Васильев, О.Ю. Воронина и др. СПб.: «Академия», 2005. 352 с.

*Сөләйман.* Сүтелә йомгак... Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 209 б.

*Тарханова Ф.* Капка // Казан утлары. 2017. №5. Б. 99.

Терминология современного зарубежного литературоведения. (Страны Западной Европы и США) / отв. ред.: Ильин И.П., Цурганова Е.А. М.: ИНИОН, 1992. 218 с.

*Юсупова Н.М.* 2017 нче елда татар шигърияте: стиль тенденцияләре һәм жанрлар үсеше // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. Б. 66-75.

*Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И.* Современная татарская поэзия / Национальные литературы республик Поволжья (1980 – 2010 гг.). Барнаул, 2012. С. 118-123.

*Latypova A.V., Sayfulina F.S., Sheyanova S.V.* Genre paradigm features in R. Idiatullin's poetry / Turismo: Estudos &Práticas (UERN), Mossoró/RN, Caderno Suplementar. 2019. T. 1. Pp.1-7.

*Latypova A., Khabutdinova M., Zakirzyanov A.* The question about ethnic identity of the modern tatar poets of the republic of Bashkortostan (based on the lyrics of Maris Nazirov) / The Turkish Online Journal of Design, Art and Communica-tion. TOJDAC. April 2017. Special Edition. Pp. 917 – 921.

# ТАТАРСКАЯ ПОЭЗИЯ НАЧАЛА XXI ВЕКА: ТРАДИЦИИ И ПУТИ ОБНОВЛЕНИЯ

**Нурфия Марсовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

В статье на основе анализа стихотворений, созданных в последние годы, раскрываются ключевые тенденции в развитии современной татарской поэзии, выявлена роль традиций в ней, определены пути обновления. Некоторые из произведений вводятся в научный оборот впервые. На основе герменевтического анализа определяется место поэтов и их произведений в литературном процессе, выявлены их открытия и находки в области поэтики, охарактеризованы переживаемые татарской поэзией изменения. В этом состоит актуальность и новизна данного исследования. Цель исследования – выявить ключевые тенденции в современной татарской поэзии на основе изучения концепции личности, творческого направления, системы жанров, традиций в тематике и проблематике в области поэтики и путей их обновления. Доказано, что в реалистических произведениях усиливается критическая составляющая, преобладающей становится национальная тематика, гражданская позиция раскрывается в философском ключе, обновляется концепция личности. Чтобы донести до читателей свою критическую оценку, поэты прибегают к иносказанию, демифологизации и интертекстуальности. Выявлена взаимообусловленность обновления системы жанров, форм, концепции личности в татарской поэзии с углублением философского начала в гражданской позиции постреализма. В рамках постмодернистских экспериментов поэты обращаются к изображению депрессивного фона современной жизни, к мозаичности эстетических форм, в передаче содержания придерживаются «игрового» отношения к действительности, что приводит к смешению поэтического языка. Для романтических произведений характерно углубление философского начала, религиозных мотивов, преобладание размышлений о непреходящих ценностях жизни, изменения в концепции личности, усиление эстетических поисков.

**Ключевые слова:** современная татарская поэзия, концепция лирического героя, образ, жанр, литературное направление, поэтические приемы.